ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

03 декабр 2021 ел № 86

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы карарлары белән расланган муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 78 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда шикаять бирүнең судка кадәр тәртибе, әгәр федераль закон белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләр турында башкасы билгеләнмәгән булса, кулланылмый.

1.2. Нигезләмәнең 4.2 - 4.6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Нигезләмәнең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга гомуми таләпләр турында федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль контрольне

гамәлгә ашырганда шикаятьләр бирүнең судка кадәр тәртибе кулланылмый.

2.2. Нигезләмәнең 6.2 - 6.21 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. Нигезләмәнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга гомуми таләпләр турында федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда шикаятьләр бирүнең судка кадәр тәртибе кулланылмый.

3.2. Нигезләмәнең 4.2 - 4.6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, әмма 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин